КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 2 июнь г.Казань № 330

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында» 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән расланган «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия төзү хакында» 2016 ел, 16 апрель, 235 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 октябрь, 801 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан И.Ш.Халиковны, С.Г.Болотаевны, Э.Н.Фатыйхованы, И.А.Шигинны чыгарырга;

Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

ввести в состав Комиссии:

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевичны | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комиссия рәисен |
| Афонин Андрей Геннадьевичны | «Татарстан Республикасы эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе генераль директорын (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бәшәрова Фәридә Рәшид кызын | «Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге генераль директорын (килешү буенча) |
| Сираҗиева Равилә Раид кызын | «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесен |
| Хөснетдинова Фәридә Наил кызын | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының муниципаль берәмлекләрне үстерү бүлеге башлыгын; |

Шәвәлиев Дилүс Рәсим улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешма директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\330.docx